ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.08.2019 Олы Кайбыч авылы № 382

Опека һәм попечительлек органынын
аерым вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы
оешмалар эшчәнлеген контрольдә тоту
Тәртибе турында Нигезләмәне раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 18 нче маенда чыккан 423 нче номерлы «Балигъ булмаган гражданнарга карата опека һәм попечительлек алып баруның аерым мәсьәләләре турында» карарына, Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2019 елның 10 гыйнварындагы 4 номерлы «Балигъ булмаган гражданнарга карата опека һәм попечительлек алып баруның аерым мәсьәләләрен гамәлгә ашыру турында» боерыгына таянып, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР КЫЛА:

1.Балигъ булмаганнарның опекуннары яки попечительләре булырга яки Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән башка рәвешләрдә ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә тәрбиягә алырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча опека һәм попечительлек органының аерым вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы оешмалар эшчәнлеген контрольдә тоту тәртибе турындагы Нигезләмәне расларга (Кушымта).

2.Әлеге карарны хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) бастырырга һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Башкарма комитет Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.А.Биккуловага йөкләргә.

Җитәкче А.Н. Макаров

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
2019е. 26 августындагы 382 номерлы
карарына Кушымта

## Балигъ булмаганнарның опекуннары яки попечительләре булырга яки Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән башка рәвешлрдә ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә тәрбиягә алырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча опека һәм попечительлек органының аерым вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы оешмалар эшчәнлеген контрольдә тоту тәртибе турында Нигезләмә

### 1. Гомуми нигезләмәләр.

1.1. Әлеге тәртип 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 18 маендагы 423 нче номерлы карары белән расланган Мәгариф оешмалары, медицина оешмалары, социаль хезмәтләр күрсәтүче башка оешмалар, яисә башка оешмалар, шул исәптән ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар өчен оешмалар тарафыннан балигъ булмаган гражданнарга карата опека һәм попечительлек органнарының аерым вәкаләтләрен гамәлгә ашыру кагыйдәләренең 5 пунктын, һәм Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2015 елның 13 мартындагы 235 нче номерлы боерыгы белән расланган Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләгән затларны эшчәнлекне оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибенең 24 пунктын гамәлгә ашыру максатыннан эшләнгән, һәм балигъ булмаган гражданнарны опекага яки попечительлеккә алырга яисә ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны Россия Федерациясенең гаилә законнарында билгеләнгән башка формаларда гаиләгә тәрбиягә алырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча опека һәм попечительлек органының аерым вәкаләтләрен тапшыру турында Казан шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан шартнамәләр төзелгән оешмаларның эшчәнлеген контрольдә тотуны гамәлгә ашыру кагыйдәләрен билгели (алга таба – опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча вәкаләт).

1.2. Россия Федерациясе Мәгариф Министрлыгының «Балигъ булмаган гражданнарга карата опека һәм попечительлек алып баруның аерым мәсьәләләрен гамәлгә ашыру турында» 2019 елның 10 гыйнварындагы 4 номерлы боерыгы белән билгеләнгән тәртиптә опекуннар булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча оешма эшчәнлеген контрольдә тоту Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге тарафыннан гамәлгә ашырыла.

1.3. Опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча оешма эшчәнлеген контрольдә тоту мондый оешма эшчәнлегенә тикшерүләр үткәрү юлы белән гамәлгә ашырыла.

## 2. Опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы оешма эшчәнлеген тикшерүне үткәрү регламенты

2.1. Опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча вәкаләтләрне тормышка ашыручы оешма эшчәнлеген тикшерү Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек буенча аерым дәүләт вәкаләтләрен башкаручы опека һәм попечительлек органының вәкаләт бирелгән вазифаи заты (муниципаль хезмәткәр) тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 18 маендагы 423 нче номерлы «Балигъ булмаган гражданнарга карата опека һәм попечительлек алып баруның аерым мәсьәләләре турында» карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

2.2. Опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча оешма эшчәнлеген Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының бер вазыйфаи заты (муниципаль хезмәткәр) яисә опека һәм попечительлек буенча аерым дәүләт вәкаләтен башкаручы Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының кимендә ике муниципаль хезмәткәре составындагы комиссия башкара ала, аларның берсе комиссия рәисе булып тора.

2.3. Опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы оешма эшчәнлеген тикшерү планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин:

2.3.1. Планлы тикшерү булып тикшерү планына кертелгән, тиешле календарь елына формалашкан һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расланган тикшерү тора.

2.3.2. Килешү нигезендә балигъ булмаган гражданнарның опекуннары яки попечительләре булырга теләк белдергән яки ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны гаиләгә тәрбиягә алырга теләк белдергән гражданнарны әзерләү өчен юллама бирү очрагында бер оешманы планлы тикшерү елга бер тапкырдан да ешрак үткәрелми.

2.3.3. Планлы тикшерү оешманың урнашу һәм эшчәнлек алып бару урыны буенча (урынга чыгып тикшерү) үткәрелә.

2.4. Тикшерү планына кертелмәгән тикшерү планнан тыш тикшерү булып тора.

2.4.1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты карары нигезендә түбәндәге очракларда планнан тыш тикшерү үткәрә:

- опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда оешма тарафыннан аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга гражданнардан шикаять килгән очракта;

- дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, башка оешмалардан һәм гражданнардан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы оешма эшчәнлегендә гамәлдәге закон нормаларын бозу турында мәгълүмат килгән очракта.

Планнан тыш тикшерү Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының планнан тыш тикшерү үткәрү турындагы карары нигезендә, әлеге пунктта күрсәтелгән очраклар килеп туган очракта, чикләнмәгән сандагы тапкыр урынга барып, йә урынга чыкмыйча үткәрелә.

2.5. Опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы оешма эшчәнлеген тикшергәндә опека һәм попечительлек органы вазифаи затының яисә комиссия әгъзаларының түбәндәгеләргә хокукы юк:

- күрсәтелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга кагылмаган гамәлдәге закон таләпләренең үтәлешен тикшерүгә;

- тикшерү предметына кагылмаган документларны, мәгълүматны бирүне таләп итүгә;

- әлеге тәртип белән билгеләнгән тикшерүне үткәрү срокларын арттырырга.

2.6. Опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча оешма эшчәнлеген тикшерүне үткәрү максатларында вазыйфаи зат (муниципаль хезмәткәр) түбәндәге мәгълүматларны үз эченә алган тикшерү үткәрү турында мәгълүмат хатын оештыруга җибәрүне тәэмин итә:

- тикшерү формасы турында (урынга чыгып, урынга чыкмыйча);

- тикшерү төре турында (планлы, планнан тыш);

- тикшерүне үткәрү вакыты турында (башлану һәм тәмамлану датасы).

Тикшерү үткәрү турындагы мәгълүмати хат оешмага тикшерү башланган көнгә кадәр 3 (өч) эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелә.

2.7. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының вазыйфаи заты (муниципаль хезмәткәр) йә комиссия әгъзалары түбәндәгеләргә хокуклы:

- оешманың вазыйфаи затларыннан тикшерү максатларына ирешү өчен кирәкле барлык документларын (мәгълүматны) сорарга, шулай ук тикшерү барышында барлыкка килә торган мәсьәләләр буенча язма һәм телдән аңлатмалар таләп итәргә;

- тикшерү материалларына кертү өчен тикшерү предметына кагылышлы документларның күчермәләрен алырга.

2.8. Урынга чыгып тикшерү (күчмә тикшерү) үткәрүнең гомуми вакыты 2 (ике) эш көненнән дә артмаска тиеш.

2.9. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты вазыйфаи затлары тарафыннан, йә комиссия тарафыннан узганнан соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча вазыйфаи затларның (муниципаль хезмәткәрләрнең) материалларын, документларын һәм аңлатмаларын өйрәнү нәтиҗәләреннән чыгып күчмә тикшерү тикшерү акты төзелә.

2.9.1. Тикшерү акты кәгазьдә ике нөсхәдә рәсмиләштерелә.

2.9.2. Тикшерү актында түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

тикшерү актын төзү датасы, аны уздыру көннәре санын күрсәтеп, урыны һәм вакыты турында;

- тикшерү төре һәм формасы турында;

- тикшерү нинди карар нигезендә үткәрелгән Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты шул карарының датасы һәм номеры турында;

- Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының вазыйфаи заты (муниципаль хезмәткәр) йә тикшерү уздыручы комиссия әгъзалары (комиссия рәисе күрсәтеп) турында;

- - оешма тарафыннан тикшерү үткәрү өчен тапшырылган (тапшырылмаган) документлар (мәгълүмат) турында;

- опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү вәкаләтләрен тормышка ашырганда оешма эшчәнлегендә ачыкланган хокук бозу очраклары, аларның характеры һәм эчтәлеге турында;

- оешма тарафыннан тикшерү тәмамланган датага опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча ачыкланган җитешсезлекләр һәм җитешсезлекләрне бетерү турында;

- тикшерү нәтиҗәләре турында гомумиләштерелгән мәгълүмат һәм нәтиҗәләр;

- оешма җитәкчесенең тикшерү нәтиҗәләре белән танышудан яки танышудан баш тарту турында белешмәләре.

2.9.3. Тикшерү акты Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының вазыйфаи заты (муниципаль хезмәткәре) йә комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан раслана. Тикшерү актына комиисиянең кайбер әгъзалары кул куя алмаган очракта, тикшерү актында комиссиянең аерым әгъзалары тарафыннан тиешле имза булмау сәбәбе турында аңлатма ясала.

2.9.4. Тикшерү актына тикшерүгә, шул исәптән ачыкланган бозулар өчен җавап бирүче оешманың вазыйфаи затларының аңлатмаларына кагылышлы документлар яки аларның күчермәләре теркәлә.

2.9.5. Тикшерү актының бер нөсхәсе Башкарма комитет җитәкчесе раслаганнан соң 5 эш көненнән дә соңга калмыйча оешма җитәкчесенә җибәрелә.

2.10. Урынга чыкмыйча тикшерү Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының вазыйфаи заты (муниципаль хезмәткәрләр) яки комиссия тарафыннан булган документларны, шулай ук оешмадан соратып алынган һәм алына торган документларны, оешманың вазыйфаи затларының аңлатмаларын карап тикшерү юлы белән үткәрелә.

2.10.1. Оешма җитәкчесе опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча оешма эшчәнлегенә кагылышлы барлык соратып алына торган документларны тикшерү үткәрү турында мәгълүмат хатында күрсәтелгән вакытта тапшырырга тиеш.

2.10.2. Урынга чыкмыйча тикшерү нәтиҗәләре буенча Башкарма комитет тарафыннан тикшерү нәтиҗәләре турында белешмә әзерләнә. Белешмә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының вазыйфаи заты (муниципаль хезмәткәр) яки комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан килештерелә. Белешмә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе белән килештерелгәннән соң 3 (өч) эш көненнән дә соңга калмыйча заказлы хат белән оешмага җибәрелә.

Балигъ булмаганнарның опекуннары яки попечительләре булырга яки Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән башка рәвешләрдә ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә тәрбиягә алырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча опека һәм попечительлек органының аерым вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы оешмалар эшчәнлеген контрольдә тоту тәртибе турында Нигезләмәгә Кушымта

Балигъ булмаган балаларны опекага яки попечительлеккә алырга яисә ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны Россия Федерациясенең гаилә законнарында билгеләнгән башка формаларда гаиләгә тәрбиягә алырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча опека һәм попечительлек органының аерым вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы оешмалар эшчәнлеген контрольдә тоту буенча
тикшерүләр планы

| Тикшерүләр даимилеге | Тикшерү үткәрү ае | Тикшерү үткәрү срогы |
|---|---|---|
| Елга 1 тапкыр | октябрь | 1 көн |